РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» июня 2021 ел г. Альметьевск № 22

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларын гамәлдән чыгару турында

Әлмәт муниципаль районының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча бер өлешен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2021 елның 12 маендагы 31 номерлы карары, Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча бер өлешен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында Әлмәт шәһәр Советы тәкъдимен кабул итү хакында» 2021 елның 12 маендагы 54 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарларын гамәлдән чыгарырга:

«Торак (торак булмаган) урынны торак булмаган (торак) урынга күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 6 декабрендәге 92 номерлы;

«Күпфатирлы йорттагы урыннарны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү (килештермәү) турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 26 июнендәге 62 номерлы;

«Күпфатирлы йорттагы урыннарны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү (килештермәү) турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 26 июнендәге 62 номерлы Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 8 ноябрендәге 96 номерлы.

2. Район Башкарма комитетның Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Р. Исхаков